# Чишмә башы

***Бөек Татар шагыйре***
***Габдулла Тукайның   тууына 140 ел***

***Тукай-безнең горурлык***

Без горурланып әйтә алабыз:бөек Тукай безнең авылда яшәгән. Өчиле авылы ятим Габдулланы берничә тапкыр ач үлемнән алып калган.Булачак шагыйрьне дөньяга тудырган,аны күкрәк сөте белән имезеп үстергән,баласына шагыйрьлек сәлате бүләк иткән изге ана - Өчиледә туып үскән кыз. Ул шушы авылның Зиннәтулла хәзрәт кызы Бибимәмдүдә апа кызы.Тукайга шагыйрьлек сәләте дә әнисеннән күчкән булырга тиеш. Чөнки Мәмдүдә апа үзе дә кирәк чакта шигырь белән җавап бирә торган сүзгә оста хатын булган. Зиннәтулла хәзрәт тә шигырьләр язгалаган. Олы кызы Мәмдүдә яшьли үлеп киткәч,аңа багышлап, шигырь чыгарган. Димәк, Өчиле авылы Тукайга шагыйрьлек талантын да бүләк иткән дип әйтә алабыз.

(Тукайның  Өчиледәге  тормышы турында тулырак 2 биттә  урнашкан Зыятов Фәрхәт абый язмасын укып таныша аласыз)



## Шагыйрьнең Өчиледә соңгы тапкыр булуы турында…

1911 елның кышында шагыйрьнең сәламәтлеге бик нык какшый, аны Казанның Клячкин хастаханәсенә салалар. Аны дәвалаучы докторлар Тукайга авыл һавасында булырга, яңа сауган җылы сөт эчәргә, тынычлыкта калырга тәкъдим итәләр. Ул шушы вакытта, тормышы өчен иң хәлиткеч көннәрдә, Үзенең нинди хәлдә булуы турында хат язып, бик ашыгыч рәвештә Өчиледәге Кәбир абыйсын (ул аны берадарым муллам дип атый) чакыртып ала. Ә Кәбир Мәмдүдә апаның әтиләре бер, әниләре башка булган туган энесе. Хатны алган көнне үк Кәбир мулла (бу вакытта инде Зиннәтулла хәзрәт вафат булган, муллалык эше аның улы Кәшфелкәбиргә калган була) Казанга Тукай яткан әлеге Клячкин хастаханәсенә килә. Шагыйрь абыйсыннан: «Җиңги нинди табигатьтә, әгәр дә беркадәр вакыт мин сезгә кайтып ятсам, миннән тарсынмасмы?» — дип сорый. Әнә шулай 1911 елның декабрендә Тукай, дәваланып яту өчен, Өчилегә Кәбир мулла белән Рәбига абыстай гаиләсенә кайта. Бу кайтуыннан шагыйрь бик канәгать кала, дусты Гыйльметдин Шәрәфкә язган хатында мондый юллар бар: «Ниһаять авылга кайтып җиттем. Сандык шикелле кечкенә генә, нараттан салган ак өй үземнеке. Көненә ике ягылганга, бик җылы, тәмам чишенеп йоклыйм. Иртә белән яңа сауган җылы сөт эчәм. Гомумән, тегенди сөтне дә күбрәк эчәргә тырышам. Фәкать әле авылларда сыерлар бозауламаган икән. Хәзер үк үземдә бераз яхшыру вә хәлләнү сизә башладым. Казаннан алып кайткан даруларны да истигъмаль итәм. Эшләр болай барса, бер-ике айдан сихәтләнермен кебек…» (Габдулла Тукай. – 5 том. – Казан: Тат. кит. нәшр., – 1986. – 111 б.).

Аның Өчиледә дәваланып ятуы турында аны тәрбияләгән Рабига Әмирова язмасыннан укырга мөмкин. (Тукай турында истәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., – 1986. – 160 б.).

Өчиледә Габдулла Тукай җанына, тәненә дәва гына түгел, иҗатына да илһам таба. Үзе булган авылларда ул беркайчан да иҗат белән шөгыльләнмәгән, ә бу соңгы кайтуында Өчиледә 13-14 шигырен яза.

Галим, язучы Ибраһим Нуруллин шагыйрьнең Өчиледә булу тарихы турында “Чуар киез итек” хикәясендә бик матур сурәтли. Бу юлы Тукай безнең Өчиледә 1911 елның декабреннән 1912 елның март аена кадәр була, туганнары җәйгә кадәр торырга бик кыстасалар да, ул: «Җәйгә яңадан кайтырмын. Җиңгинең болай тарсынмаслыгын белгән булсам, узган җәй үк кайткан булыр идем», — дип, Казанга кайтып китә. Ни кызгыныч, бу Тукаевның Өчилегә соңгы кайтуы була.



Шагыйрьнең Өчиледә авырып ятуы турында җиңгәсе Рабиганың (ул — 1886 елгы, ягъни Тукайның яшьтәше, ире Кәбир, Тукайның абыйсы 1885 елгы, ягъни шагыйрьдән бер генә яшькә олы) үзе сөйләгәннәрне укый аласыз («Сүнмәс утлар балкышы» ,74 б.). Шунысы да дикъкатькә лаек: үләр алдыннан бөегебез Клячкин хастаханәсендә Рабига җиңгәсе биреп җибәргән мендәрләрдә яткан.

# Укучылар иҗаты



**Без-Тукай оныклары**

Без-Тукай оныклары

Әкият,шигырьләрең аша

Күпме тәрбия алдык без.

Бик күп иҗат җимешләрең

Күңелдән дә беләбез.

Синең йөргән сукмаклардан

Менә без дә йөрибез.

“Туган тел”не,”Тәфтиләү”не

Рәхәтләнеп көйлибез.

Һәр тарфта горурланып

Без дә әйтә алабыз:

Тукай-безнең авылныкы!

Тукай-безнең бабабыз!

Минһаҗева Илүзә

**Матур авыл-Өчиле**

Туган авылым-Өчиле
Бигрәк матур авыл ул.
Җәйләр житкәч табигате
Күз яуларын алырлык.
Кызыл.сары чәчкәләргә
Күмелә болыннары,
Урамнарын моңга күмә
Сандугач тавышлары.

Сабирова Азалия

**Язгы җыр**

Тәрәзәмне черт-черт
Гүзәл яз чиертә.
Бакчамдагы гөлләр
Чәчәккә күмелә.
Бар дөнья яшәрә,
Кошкайлар гөрләшә.
Кояшкай елмаеп,
Безгә нур өләшә.
Җыелып һәммбез
Кырларга чыгабыз.
Тургайлар моңына
Кушылып җырлыйбыз.

Шакирова Ралинә

